| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОКУВАКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ КУАК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2022 елның 7 ноябре Иске Куак № 27

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзеклəндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм авыл җирлеге территориясенең тиешле санитар торышын тәэмин итү, авыл җирлеге территориясен пычратудан саклау чараларын тормышка ашыру максатыннан, Иске Куак авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куак түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 142 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«142. Умарталарны тоту өчен урыннар (алга таба - умарталыклар) түбәндәге ераклыкта булырга тиеш:

Торак пунктларда яки гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территорияләрендә (алга таба - бакчачылык яисә яшелчәчелек территорияләре) очу юлын әлеге участоклар чикләреннән капма каршы якка юнәлдереп күршедәге җир кишәрлекләре чикләреннән кимендә 3 метр ераклыкта яки умарталыкларны башка җир кишәрлекләреннән 2 метрдан ким булмаган койма белән аерып алу шарты булганда очу юлын ераклык һәм юнәлеше буенча чикләүләрсез»;

б) 134 пунктта «башка зат» сүзләреннән соң «, яисә терлекләрне көтү өчен билгеләнгән территориядә терлекләрне тоту җайланмасын кулланып» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36, Зеленая урамы, 7 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Н. Сушкова

ИНН 1625001105
КПП 164901001